РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск,
423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән
Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 4 феврале № 8

**Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 21 мартындагы 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләр» 13 статьясындагы 13.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.1. Муниципаль хезмәткәр бурычлы:

1) Россия Федерациясе Конституциясен, федераль конституциячел законнарны, федераль законнарны, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, муниципаль берәмлек Уставын һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

2) вазыйфаи инструкция нигезендә вазыйфаи бурычларны үтәргә;

3) вазыйфаи бурычларын башкарганда, расасына, милләтенә, теленә, дингә мөнәсәбәтенә һәм башка шартларга бәйсез рәвештә, кеше һәм гражданның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен, шулай ук оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәргә;

4) җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкцияне, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;

5) вазыйфаи бурычларны тиешенчә үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен даими күтәреп торырга;

6) федераль законнар тарафыннан саклана торган дәүләт һәм башка серләрне тәшкил итүче белешмәләрне, шулай ук вазыйфаи бурычларны үтәү белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган белешмәләрне, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә кагылышлы яисә аларның намусына һәм абруена кагылучы белешмәләрне таратмаска;

7) дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне, шул исәптән аңа вазыйфаи бурычларны үтәү өчен бирелгән мөлкәтне сакларга;

8) Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә үзе һәм гаилә әгъзалары турында белешмәләрне тапшырырга;

9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача формада Россия Федерациясе гражданлыгын яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгын (подданство) туктату турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, ләкин Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокуклы Россия Федерациясе халыкара шартнамәсе катнашучысы - чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылганнан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә.

10) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) язмача формада чит ил гражданлыгы (подданство) алу яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе яки чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алу турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, ләкин чит ил гражданлыгы (подданство) алган яисә яшәүгә рөхсәт кәгазе яки чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;

11) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда һәм башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, йөкләмәләрне үтәргә, тыюларны бозмаска;

12) яллаучы (эш бирүче) вәкиленә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган вазыйфаи бурычларны үтәгәндә шәхси кызыксынучанлык турында язмача хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау буенча чаралар күрергә мөмкин.»;

1.2 «Муниципаль хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигезләр» 18 статьясындагы 18.1 пунктының 3 пунктчасында «һәм 15.1» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.3 «Муниципаль берәмлектә кадрлар эше» 28 статьясына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Түбән Кама шәһәре җирле үзидарә органнары кадрлар эше буенча аерым функцияләр Түбән Кама муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшырылырга мөмкин. Бу очракта, тапшырылган функцияләр, төзелгән килешү нигезендә, Түбән Кама муниципаль районының җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

М.В.Камелина